

# Сагышларым, табышларым...

Хәмит Латыйпов – Яр Чаллы шәһәренең иң үзенчәлекле рәссамнарыннан берсе. Ул майлы буяулар белән (живопись), графика, агачтан уеп эшләү сәнгате (резьба), керамикада һәм, гомумән, сәнгатьнең төрле өлкәләрендә эшли. Халкыбызның рухы, борынгы бабаларыбызның энергиясе, көче аның әсәрләрендә кайтаваз булып чагыла. Күптән түгел рәссам-шагыйрьнең берничә альбомы дөнья күрде.

«Сагышларым» – шигырь һәм графикадан торган китап. Сагыш, моң тулы бу китапка Х. Латыйповның җиде йөздән артык шигыре һәм 940 рәсем графикасы кергән. Автор, шигърият белән рәсем сәнгатен берләштереп, катлаулы тирән рухи моң тудыра алган. Китапны автор газиз кешесенә – җиде айлык вакытында югалткан әнисе Хаманнуллина Муфавазага багышлаган. Шул рәвешле рәссам гомерлек җан газабын басарга тырышкан, күрәсең.

«Песнь дерева» альбомында Х.Латыйпов үзенең агачтан уеп ясаган эшләрен, эзләнүләрен күрсәтә. Панноларында, сыннарында, декоратив әсәрләрендә кеше һәм табигатьнең үзенчәлекле гармониясен тудыра. Материалның (агач) һәм инструментның уеп эшләү мөмкинлекләрен күрсәтә, агачка зур хөрмәт белән карарга өйрәтә. Бу альбомга 156 төсле рәсем, 461 аклы-каралы графика кергән.

«Живопись и графика» альбомы акрил буяулары белән язган җитмешләп әсәрдән һәм графика эшләреннән тора. Автор аларны берләштереп «Туган җирдә» дигән исеме белән атый. 2020 елның кышында язган гаҗәеп


Сагышларым
Хамит Латыпов
Живопись
и графика
«Родная земля»
Пастель
шәмәхә төсләр эзе
Хәмит
Латыйпов
Хәмит Латыйпов
Керамика
Утта яралган моң
Песнь древа
Графика. Резьба по дереву
Хәмит Латыйпов
Роспись
Уелган бизәкләр
Резьба по дереву
Хәмит Латыйпов
Эзләнүләр
Поиски и эксперименты

үзенчәлекле, халыкчан рухтагы стиль сериясе безгә тагын төрки-татар тамырларыбызны искә төшерә. Бу – авторның Көнчыгышның бөек миниатюраларын хәтерләткән үзенчәлекле стиль табышы. «Живопись» альбомына 94 төсле, 94 аклы-каралы биттән торган график эшләр кергән.

«Пастель» альбомына шул техникада эшләгән эшләр кергән. Хәмит Латыйпов материал белән идеянең бердәм агылыш юлларын, гармониясен эзли, бик күп экспериментлар ясый. Бу уникаль техникада ул ун елга якын иҗади хезмәт куя. 371 төсле, 416 аклы-каралы графика кергән.

«Керамика» альбомында керамик эшләре белән бергә бик күп түгәрәк графика эшләре дә тәкъдим ителгән. Бу сәнгатьнең ике юлын берләштереп, автор гаҗәеп киң дөнья ачкан. Гомумән, аның эшләрендә дөнья әле генә барлыкка килгән яңалык булып тоела, кабул ителә. Рәссамның әсәрләре аша без үткәннәргә, борынгы тарихыбызга кире кайтып, шул чорларда йөрибез кебек. «Керамика» альбомына 89 төсле рәсем, 442 аклы-каралы график рәсем тупланган.

«Эзләнүләр» альбомына авторның башлангыч эшләре, төрле материалдагы иҗади эзләнүләре кергән. Бу альбомда Хәмит Латыйповның шигырьләре дә урын алган. Сынлы сәнгать белән шигырьләрнең бер-берсен баетып янәшә яшәүләре укучыда кызыксыну уята. «Эзләнүләр» альбомына 146 төсле рәсем, 241 аклы-каралы график рәсемнәр кергән.

«Роспись» (шигырь һәм графика) альбомы – авторның фанерага, агачка, картонга төсле буяулар, пумала белән язу сәнгатендәге эзләнүләре. Элек халкыбыз сандыкларны, шкафларны бизи, тәрәзә капкачларын, өлгеләрен, капкаларны бизәкли торган булган. Кеше үзенең шәхси дөньясын, тирәлеген матурлык белән уратып алырга тырышкан. Чәчәкләр, кошлар, серле үсемлекләр белән үз мохитен матурлаган. Авторның бу альбомын шушы төр сәнгатьне кабат кайтарырга омтылышы диеп аңларга кирәк. Биредә 141 төсле рәсем, 467 аклы-каралы график рәсем урнаштырылган.

«Уелган бизәкләр» («Резьба по дереву») – авторның үзе бастырып чыгарган сигезенче альбомы. 227 төсле рәсем, 296 аклы-каралы рәсем кергән.

«Кайтаваз» («Эхо») сынлы сәнгать һәм шигырьләр альбомына Хәмит Латыйповның 2781 аклы-каралы графикасы, 685 төсле рәсемнәре, 116 аклы-каралы фото тупланган. Шулай ук бу альбомга 304 шигырь, авторның сәнгать турындагы 133 әйтем-фикерләре урын алган. 914 биттән торган әлегә альбом бары бер экземплярда чыккан. Әлбәттә, бу хезмәт дәүләт тарафыннан лаеклы бәясен алып, зур тираж белән дөнья күрсә, бик отышлы булыр иде.

Гомумән, әлеге альбомнар берничә данәдә генә, автор хисабына чыгарылган. Киләчәк буыннар өчен аларның дәүләт нәшриятында зуррак тираж белән чыгуы кирәк, ди рәссам-шагыйрь.